СОВЕТ УРМАНЧЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Ленина, д.5, п.Зверосовхоза,
Мамадышский район,
Республика Татарстан, 422186

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ УРМАНЧЫ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ
Ленин ур., 5 нче йорт, Җәнлек совхозы поселогы,
Мамадыш районы,
Татарстан Республикасы,422186

тел.(факс): (85563) 2-12-50; e-mail: Urman.Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**
**№2-39** **от 24 сентября 2018 г**

24 сентябрь 2018 ел № 2-39

Гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм куллану мәсьәләсе буенча Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге территориясендә җирле референдумны билгеләү турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, 2004 елның 23 мартындагы 23-ТРЗ номерлы «Җирле референдум турында» Татарстан Республикасы Законының 18 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге Башкарма комитетының 2017 елның 17 сентябрендәге «Референдум үткәрү инициативасы турында» 48 номерлы карары, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 15 октябрьдәге №2-41карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салымын җыю һәм алардан файдалану тәртибе турында Нигезләмә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советының 2014 елның 15 октябрьдәге 2-41 номерлы карары белән расланган Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым акчаларын җыю һәм куллану тәртибе турындагы Нигезләмә (17.09.2018 № 5-38 карар редакциясендә) Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге Советы
КАРАР КАБУЛ ИТТЕ:

1. Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Урманчы авыл җирлеге территориясендә гражданнарның үзара салым кертү мәсьәләсе буенча җирле референдумны 2018 елның 18 ноябренә билгеләргә.

2. Җирле референдумга чыгарыла торган түбәндәге сорауны расларга: «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2019 елда 300 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

1.Җирлек чикләрендә су белән тәэмин итү: Торак пунктта су алу башнясы өчен су насосы сатып алу.Яңа пос., Кама урман хуҗалыгы т. п. ; Җәнлек совхозы п. п., Урманчы т. п., Кама урман хуҗалыгы – 2 шт., Новый п. т., Сотово т. п., чишмәләрне төзекләндерү

2.Җирлекнең торак пунктлары чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларына карата юл эшчәнлеге: Урманчы авыл җирлеге торак пунктларында җирле әһәмияттәге юлларны грейдерлау һәм кардан чистарту.

«ӘЙЕ» «ЮК».

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлегенең махсус мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районының http://mamadysh.tatarstan.ru рәсми сайтында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталында (pravo.tatarstan.ru) урнаштырырга.

5. . Әлеге карарның үтәлешен контрольгә алуны Мамадыш муниципаль районы Урманчы авыл җирлеге башлыгы А.Я.Ильинга йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Урманчы авыл җирлеге башлыгы,
Совет рәисе А.Я.Ильин